**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 май № 287

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.5.5 нче пунктча өстәргә:

«3.5.5. Түбәндәгеләр арасыннан авыл җирлегендә яши торган һәм ялгыз яисә ялгыз яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннарына:

хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә, хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә, тимер юллар һәм автомобиль юлларының фронт буе участокларында һава һөҗүменә каршы оборона, җирле һава һөҗүменә каршы

оборона объектларында, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар төзелешендә эшләгән затлар;

Бөек Ватан сугышы башында башка дәүләтләр портларында иректән мәхрүм ителгән транспорт флоты судноլары экипажлары әгъзалары;

«Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар;

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр кимендә алты ай тылда эшләгән затлар (вакытлыча оккупацияләнгән СССР территорияләрендә эшләү чорын исәпкә алмыйча);

Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\287.doc